**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.12.2020 № 1348

«Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеге хакында» Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 14 мартындагы 281 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 24 апрелендәге 17-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеге хакында» 2013 елның 14 мартындагы 281 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. «Административ хокук бозулар турында» Татарстан Республикасы кодексының 2.1 статьясы (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органының, башка дәүләт органының, җирле үзидарә органының, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, башка оешмаларның элмә тактасында үз исеме һәм элмә тактада урнаштырылырга тиешле башка төр мәгълүматны күрсәткәндә телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозуга карата), 2.4, 2.5, 2.6, 2.7, 2.8, 2.14, 2.15 статьяның 2 өлеше, 2.17, 3.2-3.7, 3.8, 3.10 (гражданнарга карата), 3.11, 3.14,3.15,3.16, 3.17, 4.4, 5.1, 5.2, 5.6 статьялары ( муниципаль районы территориясендә муниципаль транспортта йөртүне гамәлгә ашыруга карата) белән каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген 1 нче кушымта нигезендә билгеләргә»;

карарга 1 нче кушымтаны әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш һәм ТКХ буенча беренче урынбасары А.М. Шарафеевка йөкләргә.

Җитәкче Р.М. Заһидуллин

Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 24 декаберендәге 1348 нче номерлы карарына 1 нче кушымта

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.1 статьясы (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органының, башка дәүләт органының, җирле үзидарә органының, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, башка оешмаларның элмә тактасында үз исеме һәм элмә тактада урнаштырылырга тиешле башка төр мәгълүматны күрсәткәндә телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозуга карата), 2.4, 2.5, 2.6, 2.7, 2.8, 2.14, 2.15 статьяның 2 өлеше, 2.17, 3.2-3.7, 3.8, 3.10 (гражданнарга карата), 3.11, 3.14,3.15,3.16, 3.17, 4.4, 5.1, 5.2, 5.6 статьялары ( муниципаль районы территориясендә муниципаль транспортта йөртүне гамәлгә ашыруга карата) белән каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар

ИСЕМЛЕГЕ

1.Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.1 статьясында каралган административ хокук бозу турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органын, башка дәүләт органын, җирле үзидарә органын, предприятиене, учреждениене, башка оешманы чыгарган өчен ганда телләр турында Татарстан Республикасы законнары бозылуга карата) Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитетының вазыйфаи затлары:

- «Кама Тамагы муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе начальнигының(укыту-методик эш буенча )урынбасары;
- «Кама Тамагы муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенең милли мәгариф буенча методисты.

2. Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексының 2.6, 2.7 статьяларында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының вазыйфаи затлары:

- Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары;
- Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесе.

3. Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенең , Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.1, 2.4, 2.5, 2.8, 2.14, 2.15 статьясының 2 өлеше, 2,17, 3.2, 3.3, 3.4, 3.5, 3.6, 3.7, 3.8, 3.10 (гражданнарга карата), 3.11, 3.14, 3.15, 3.16, 3.17, 5.1,5.2,5.6 (муниципаль район территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль пассажирлар ташуга карата) каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлары

-бүлек башлыгы;

- бүлек башлыгы урынбасары;
- бүлекнең баш белгече.

4.Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм территориаль үсеш бүлегенең Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.1, 2.4, 2.5, 2.8, 2.14,  2.15 ст 2 өлеше, 2.17, 3.2, 3.3, 3.4, 3.5, 3.6, 3.8, 3.10 (гражданнарга карата), 3.11, 3.14, 3.15, 3.16, 3.17 статьяларында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлары :

-бүлек башлыгы;
-бүлек башлыгы урынбасары;
- бүлекнең баш белгече.

5. Кама Тамагы муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексының 4.4 статьясында каралган административ хокук бозу турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлары:

- палата Рәисе;
- палатаның әйдәп баручы белгече.

6. Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы, башка дәүләт органы, җирле үзидарә органы, предприятие, учреждение, башка оешма үз исеме һәм элмә тактасында урнаштырылырга тиешле бүтән мәгълүматларны күрсәткәндә телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозуга карата 2.1 статьяда каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи заты), 2.1, 2.4, 2.5, 2.6, 2.7, 2.8, 2.12, 2.13, 2.14, 2.15 статьяның 2 өлеше, 2.17, 3.2, 3.5, 3.6, 3.7, 3.8, 3.10 ( гражданнарга карата), 3.11, 3.14, 3.15, 3.16, 3.17, 5.1, 5.2, 5.6 (административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексының муниципаль район территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль йөк ташуларга) карата:

- Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының җәмәгать тәртибен саклау пунктлары эшчәнлеген тәэмин итүче әйдәп баручы белгеч.